## 1945 - 2015

# Бөек Җиңүгә 70




Бөек Ватан сугышы

**(1941 – 1945** еллар**)**

Проектны эшләде: 4 класс укучылары

Җитәкчесе: Мингазова Гөлназ Маратовна



# Тема: Алар илгә Җиңү алып кайтты!

***Проектның максаты:*** *Бөек Ватан сугышы елларында халкыбызның фронтта һәм тылда күрсәткән тиңдәшсез батырлыгы үрнәкләре белән яшь буынны таныштыру; буыннар арасындагы бәйләнешне ныгыту, намуслы хезмәт белән көн күргән сугыш һәм тыл ветераннарына, әби-бабайларга карата олы хөрмәт хисе тәрбияләү; гадел, тату, эшчән, игелекле булырга омтылыш уяту; эзләнү-тикшеренү эше аша балаларның Бөек Ватан сугышы турындагы белемнәрен тагын да тирәнәйтү.*

***Проектның бурычлары:***

1. *Сугыш ветераннарына, әби-бабаларыбызга карата ихтирам хисе, игътибарлылык, кайгыртучанлык тәрбияләү.*
2. *Укучыларның иҗади эшчәнлеген, мөстәкыйль фикерләвен үстерү.*
3. *Эшне оештыру һәм аны башкару сәләтен тәрбияләү.*
4. *Көндәлек матбугат, өйрәнелгән чыганаклар белән эшләү күнекмәләре булдыру.*

***Эш төркеме:*** *башлангыч сыйныф укучылары.*


***Үткәрелү вакыты:*** *сентябрь-май айлары.*

*Проектны тәкъдим итү формалары:*

*1.Әзерлек этабы:*


- *Эшне оештыру:*

*Проектны тәкъдим итү формалары:*
*1.Әзерлек этабы:*
*Эшне оештыру: газета-журналлардан материаллар эзләп, «Туган якны өйрәнү» музеена кереп, әби-бабайларның өйләренә йөреп, мәктәпкә чакырып очрашулар үткәреп, алар сөйләгәннәрдән җыйган материалларны туплау.*
*2. Төп этап:*
*Төркем белән эшләү:*
*Әзерләгән чыгышларны тыңлау, нәтиҗәләрне яклау.*
*3. Йомгаклау, нәтиҗә ясау этабы:*
*Эшкә нәтиҗә ясау, йомгаклау, бәя, үзбәя, рекомендация.*


вление по радио Заместителя Председателя Совета
Комиссаров Союза ССР и Народного Комиссара
Иностранных Дел тов. В. М. МОЛОТОВА
Алар илгә
Җиңү алып кайтты!


1941 - 1945
Очрашу мизгелләре
Сугыш хатирәләрен барлап...

# Эзләнүләр...






**Дәү әнисе Сара апа сөйләгәннәрне дә Сөмбел исе китеп тыңлап торды һәм яза барды.**





**Минем гаиләдә сугыш эзләре.**

Быел илебез Бөек Җиңүнең 70 еллыгын билгеләп үтәргә җыена. Җиңү көне! Бу сүз һәркайсыбыз өчен дә чиксез кадерле .

Җиңү көне -

Халык тантанасы,

Яз төренгән янар кояшчык ,

Җир чәчәкләр тегән күкрәгенә,

Йөз балкытып карый кояшка.

Сугыш... Бу сүзнең мәгънәсен без әле аклап ...
22 июнь таңында, безнең кебек балалар татлы йо...
тасвирләре һөҗүм итә. Әлеге сугыш халык хәтер...
Чөнки сугыш илебезнең бер генә почмагына да, ...
кайгылы кулы белән кагылмыйча калмаган. Ул м...
балачагын урлаган, аларны ятим иткән. Дәү әтие...
әтиләре сугышка киткәндә туып кына калганнар.

Дәү әтием Кыямның әтисе Минһаҗев Әфтах ...
туа. 1941 елда сугышка китә. Кызыларменең була...
булган. Тверь өлкәсе Ржев районы, Гора Казеки ...

Дәү әнием Фәнүзәнең әтисе Локманов Минһаж...
Иске Әнҗерә авылында туа. 1941- елда сугышка ...



Дәү әтием Маратның әбисе турында да дәү әнием Сара сөйләгәннәрне язып алдым:

Салахов Таһир Фәсах улы 1926-елда Иске Әнҗерә авылында туа. 1943-елда сугышка китә. Сугыштан бер хаты да килми. 1944-елда бик каты яралана. Аны сугыштан яралы килеш санитарлар китерә. Ул култык таяклары белән кайта, авыртмаган бер җире булмый. Тора –бара уңайлана башлагач, авылда учетчик, бригадир булып эшли. Өйләнеп Зәйнәп апа белән 7 бала үстерәләр. Балалары: Халидә, Әлфия, Зөләйха, Мәгъсүм, Дамир, Каюм, Рәфәс. Хәзерге вакытта 4 баласы исән. Алар сирәк булса да кайткалыйлар. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Салахов Таһир Фәсах улы **Кызыл Йолдыз** ордены белән бүләкләнә. Дәү әни тагын шундый хәтерли: " Сугыштан кайткан кемнәрен кием, бер күкрәк орден-медальләр тагып дәү әниләргә кунакка килгән булган. Ул вакытта бик шатлыклы иде. Әле кайбер кешеләр аның күкрәгендә күп орден-медальләр күреп исләре киткән,"-дип сөйли дәү әнием.

Сугыш хатирәсен,батырлар даңын хәзер инде һәйкәлләр генә саклый. Алар ... тын гына сугыш афәтен башка кабатламаска чакыралар, тиңдәшсез батырлыкка ... дан җырлыйлар.

# Эзләнүләр дәвам итә...



## Музейда кунакта



Сугыш вакытында авылда калган тыл хезмәтчәннәренең дә тормыш-көнкүреше бик авыр булган.

Районыбызның Советлар Союзы Геройлары турында музей җитәкчесе Сәлим Әхәтович таныштырды.

# Сыйныфтан тыш чаралар:






**Ветераннар белән очрашу**







**“Билгесез солдат” көнен билгеләп үтү**





**“Тамчы шоу” бәйгесе**




**Бөек Ватан сугышы ветераны Рәхимов Ризатдин бабай белән очрашу мизгелләре**

# Ветераннарыбыз сөйләгәннәрдән:

*Ризатдин абый Иске Әнҗерә авылында 1923- елда туган.Бала чагында тимер-томыр белән кызыксына. Уйный-уйный узенә самокат ясап йөргән.Уз гомере буена механизатор булып эшләгән. 17 яшендә – 1942- елның 27-мартында повестка килә һәм армиягә китә. Башта Казанга баралар,аннан Ерак Көнчыгышка озаталар. Чик буенда чик саклыйлар. 1944- елда Япониягә керәләр. Анда Мохдин тимер юл станциясендә запаста торганнар. 1945- елда Япония сугыш башлый.*

- *Сез чик буенда торганда чик бозулар булдымы?*
- *Була иде.*
- *Армияда дисциплина ничек иде?*
- *Иртәнге 6 сәгатьтә торасың. Занятие була. Аннары ашау. Тагын занятие.*
- *Тәртип бозсаң җәза бирелә идеме?*
- *Эйе. Кешеләр ял иткәндә син эшлисең. Сан.частьтагы эшме, столовойда иртәнге өчен бәрәңге әрчүме…*

*Зуррак тәртип бозсаң, гаупвахтага ябалар.*
*Ризатдин абый 1947- елгача хезмәт итә. Сугышта курсәткән батырлыгы өчен «За отвагу» медале , «Победа над Японией» медале белән бүләкләнә.Ул шундый кеше- башлаган эшен төгәлләмичә ашарга да кайтмый. Бүгенге көндә дә механизатор буларак , катлаулы ремонт эшләрендә киңәшләрен бирә. Хатыны Рабига апа белән 5 кыз бала үстергәннәр.Бүгенге көндә Рабига апа белән яшиләр.*

# Сугыш турындагы язмаларыбыз район газетасы битләрендә дә урын алып тора:



## "Тыныч тормышның кадерен белегез, балалар"

Г.Минһаҗева,
Иске Әнҗерә мәктәбе укытучысы.



## И ул әрнүле сугыш хатирәләре...

1941-1945 елгы Бөек Ватан сугышы бик күпләрнең гомерләрен өзгән, меңләгән кешеләргә ачы сагыш, күз яшьләре, ятимлек китергән рәхимсез сугыш булды.

Быел Бөек Җиңүнең 58 еллыгын билгеләп үтәбез. Шул уңайдан 23 апрель көнне мәктәбебездә авылның сугыш һәм хезмәт ветераннары белән очрашу үткәрдек. Аны күп еллардан бирле мәктәптәге туган якны өйрәнү түгәрәген һәм туган як тарихы музеен җитәкләүче өлкән укытучыбыз Мәсгудә апа Хәмәтшина оештырды.

Инде елдан-ел ветераннарыбыз да кими бара. Исәннәре дә әлегә кадәр төннәрендә снаряд кыйпылчыклары, ачы сугыш яралары йөртә.

Безнең авылдан сугышка 156 кеше киткән. Шуларның 88 е генә фронттан әйләнеп кайткан. Бүген авылыбызда нибары 5 сугыш ветераны яшәп ята. Аларга исәнлек-саулык кына телибез.

Очрашуга килгән ветераннарыбыз үзләренең күргәннәрен балаларга бик теләп сөйләделәр. Укучылар да үзләрен кызыксындырган сорауларны бирел кенә тордылар.

Сугыш вакытында тылда да тормыш җиңелдән булмаган. Хатын-кызлар, үсмер балалар искиткеч авыр хезмәтләр башкарганнар. Яланаяк кырдан башак җыеп, черек бәрәңге чүпләп, кузгалак, балтырган ише үләннәр белән тукланганнар. Хезмәт ветераннары Мәсгудә апа, Хәлимә апа сөйләгәннәр дә йөрәкләргә үтеп керде. "Апамны бер килограмм бөртек урлауда гаепләп кулга алганнар. Аның яшь баласы булган. Баласыннан аерып алып апамны төрмәгә алып китәләр. Азат ителгәч тә ул баласының кайда икәнлеген белә алмый. Сабый эзсез юкка чыга". Хәлимә апа апасының шул бала өчен өзгәләнгәннәрен бик әрнеп сөйләде. Әйе, бик күп ул әрнүле сугыш хатирәләре.

Чәй табынында да ветераннарыбыз үткәннәрне искә төшереп, гыйбрәтле вакыйгаларны яңартып утырдылар, укучылар әзерләгән концертны карадылар. Икенче сыйныф укучылары, әле кечкенә булсалар да, Җиңү көненә багышлап шигырьләр язганнар иде. Шул шигырьләрен кунаклар алдында укып, аларны бик сөендерделәр.

Сугышлар гына чыга күрмәсен, шушы балалар ата-ана тигезлегендә, тынычта үссен, дип теләкләр тели-тели таралышты кунакларыбыз очрашудан.

Г.Минһаҗева,
Иске Әнҗерә мәктәбе укытучысы.

# Район буенча үткәрелгән “Рәхмәт Җиңү өчен” конкурсына җибәрелгән рәсемнәр:







**4-**касс укучысы Гизатуллин Шамил эше






**Җиңүнең 70 еллыгын каршылап...**

Бөтен дөньяны тетрәндергән миллионлаган гомерләрне өзгән, миллионлаган балаларны ятим иткән, 1941-1945еллардагы Бөек Ватан сугышында безнең бабай һәм аның улы һәлак булганнар. Безнең бабай Садреев Мифтах Садрий улы 1897 елда Иске Әнҗерә авылында туган. 1925-елларда берничә гаилә берләшеп алар Яңа Әнҗерә авылына нигез салалар. Урман кисеп, җир теплап авыл өчен урын ясыйлар, иген чәчәргә җир ясыйлар. 1930 - еллар авыл шактый зурая, колхозлары да яхшы гына эшләп китә. Колхоз "Комсомол"исемен йөртә. Ул вакытта колхозда сыер, сарык фермасы, умарталык, пар белән эшли торган тегермән, ярма яра торган тегермән, ашлык чистарта торган машиналар эшли. 1941-елның 22 июнендә башланган сугыш бөтен нәрсәнең астын-өскә китерә. Авылның бөтен эшкә яраклы ир-атлары сугышка китә. Безнең бабай да 1941 елның көзендә сугышка алына. Сугыштан аның берничә хаты гына килеп кала. Ул сугышта хәбәрсез югала. 1942-елда аның улы Сахип та 18 яше дә тулмаган килеш сугышка китә. Сугышта ул Днепр елгасын кичкәндә барган каты сугышларда һәлак булган. Үлгән чагында аңа 19 яшь кенә була. Каһәр суккан сугыш әбинең ирен, улын һәлак итә. 5 баласын ятим калдыра. Минем теләкләрем шул, мондый сугыш бүтән кабатланмасын, кан коелмасын, балалар ятим үсмәсен! Дөнья имин булсын!

Дәү әнисе Губайдуллина Румия апа сөйләгәннәрне **4-сыйныф укучысы Ведяскина Арина** язып алды.

**4-**класс укучысы
Ведяскина Арина эшләре

# Безнең уңышларыбыз:








# Бөек Ватан сугышы геройларына дан!



Медаль «Золотая Звезда». 1939 г.

